Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № X-4**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 23 апреле

«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында, шулай ук «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8.1, 12.1 маддәләре, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 маендагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе, "Федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында" Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 18 маендагы 559 номерлы Указы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 маддәсе, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы вазыйфалары исемлеген раслау турында»2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында"2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торганнарны расларга:

-«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында, шулай ук «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында Нигезләмә

- «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырырга тиешле вазыйфалар исемлеге.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 12 ноябрендәге «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында, шулай ук «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында Нигезләмәне раслау турындагы” XL-4 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2016 елның 23 апрелендәге
Х-4 номерлы карары белән
расланды

**«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында, шулай ук «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында Нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә түбәндәгеләрне тапшыру тәртибен билгели:

«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, алынган керемнәре, милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар (алга таба – керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар);

«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары һәм чыгымнары турында мәгълүматлар (алга таба – керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар).

2. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру бурычы йөкләнә:

муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданга (алга таба - граждан);

«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче, Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары белән раслана торган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелмәгән (алга таба - вазыйфалар исемлеге) һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы, вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәргә (алга таба - вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфага кандидат).

Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру бурычы хисап елының 31 декабренә торышы буенча муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәргә йөкләнә (алга таба - муниципаль хезмәткәр).

3. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат формасын раслау һәм Россия Федерациясенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча

тапшырыла:

гражданнар тарафыннан - муниципаль хезмәткә кергәндә;

вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфаларга кандидатлар тарафыннан - вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларына билгеләгәндә.

4. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматлар муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмә формасын раслау турында» Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

5. Муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләгәндә граждан түбәндәгеләрне тапшыра:

а) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган керемнәре (элеккеге эш урынындагы яисә сайланулы вазыйфаны биләү урынындагы керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында мәгълүматлар, шулай ук милек хокукындагы мөлкәте турында һәм муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) карата мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар;

б) гражданның муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) алынган керемнәре турында мәгълүматлар, шулай ук гражданның муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар.

6.Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфага кандидат әлеге Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыра.

7. Муниципаль хезмәткәр ел саен түбәндәгеләрне тапшыра:

а) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан алынган керемнәре (акчалата тотуны, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында мәгълүматлар, шулай ук милек хокукындагы мөлкәт турында һәм хисап чоры ахырына торышы буенча үзенең мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар;

б) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) алган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) керемнәре турында мәгълүматлар, шулай ук алар милек хокукында булган мөлкәт турында һәм хисап чоры ахырына аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында

мәгълүматлар;

в) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) турында мәгълүматлар, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми керемennән артып китсә һәм әлеге алыш-бирешләрне башкару чыганаклары хакында.

8. Әлеге Нигезләмәнең 5, 6 һәм 7 пунктларында каралган мәгълүматлар җирле үзидарә органының (муниципаль орган) кадрлар хезмәтенә (кадрлар эше буенча белгечкә) тапшырыла. Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы - Балык Бистәсе муниципаль районы Советы рәисе исеменә керемнәре, чыгымнары һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыра.

9. Әгәр граждан яисә муниципаль хезмәткәр алар тарафыннан җирле үзидарә органының (муниципаль органның) кадрлар хезмәтенә (кадрлар эше буенча белгече) тапшырган мәгълүматларда нинди дә булса мәгълүмат чагылдырылмаган яки тулысынча чагылмаган, яки хаталар булган очракта, алар әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә төгәлләштерелгән мәгълүматларны тапшырырга хокуклы.

Граждан әлеге Нигезләмәнең 3 пунктының икенче абзацы нигезендә мәгълүматлар тапшырылган көннән алып бер ай эчендә төгәлләштерелгән мәгълүматларны тапшырырга мөмкин. Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфага кандидат әлеге Нигезләмәнең 3 пунктының өченче абзацы нигезендә мәгълүматлар тапшырган көннән алып бер ай эчендә төгәлләштерелгән мәгълүматларны тапшырырга мөмкин. Муниципаль хезмәткәр әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә төгәлләштерелгән мәгълүматларны тапшырырга мөмкин.

10. Объектив сәбәпләр аркасында муниципаль хезмәткәрләргә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырмаган очракта, әлеге факт муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын (низагын, каршылыгын) җайга салу буенча тиешле комиссия утырышында каралырга тиеш.

11. Әлеге Нигезләмә нигезендә граждан һәм муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү кануннар нигезендә гамәлгә ашырыла.

12. Әлеге Нигезләмә нигезендә граждан һәм муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматлар, әгәр федераль закон белән алар дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларга кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы мәгълүматлар була.

Әлеге мәгълүматлар җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесенә һәм җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларына, федераль

законнарда каралган очракларда, вазыйфага билгеләнү һәм муниципаль хезмәткәрләр вазыйфасыннан азат итү вәкаләтләренә ия булган затларга, шулай ук федераль законнарда каралган очракларда башка вазыйфаи затларга тапшырыла.

13. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (катнашу өлешләре, оешмаларның устав (туплау) капиталларында пайлар) сатып алу буенча килешүләр башкарылган акча алу чыганаклары турында мәгълүматлар соңгы өч елда муниципаль хезмәт вазифасын биләгән затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китә, хисап чорына кадәрге чорда, Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырыла: http:// ribnaya-sloboda.tatarstan.ru., законнарда билгеләнгән тәртиптә, ә бу мәгълүматлар Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә булмаган очракта, алар соравы буенча бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла.

14. Вазыйфаи вазыйфаларына әлеге Нигезләмә нигезендә граждан һәм муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматлар белән эшләү кергән муниципаль хезмәткәрләр аларны бүлүдә яки Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда файдалануда гаеплеләр Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

15. Гражданның яисә вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфага кандидат тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар, муниципаль хезмәткәрләргә ел саен тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар, шулай ук әлеге мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшенә кушып (теркәп) бирелә. Җирле үзидарә органының (муниципаль органның) кадрлар хезмәтенә (кадрлар эше буенча белгече) үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырган граждан яисә вазыйфага кандидат вазыйфаларына муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнмәгән очракта, мондый мәгълүматлар күрсәтелгән затларга язма гаризалары буенча башка документлар белән бергә кайталар.

16. Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белә торып ялган мәгълүматлар тапшырмаган яисә тапшырмаган очракта граждан муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнә алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителә яки Россия Федерациясе законнары нигезендә башка төр дисциплинар җаваплылыкка тартыла.

Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үз чыгымнары турында тулы булмаган яисә дөрес булмаган мәгълүматлар бирелү йә хатынының (иренең) һәм

балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында алдан ук тулы булмаган яисә дөрес булмаган мәгълүматлар тапшыру, мондый мәгълүматларны тапшыру мәҗбүри булган очракта, аларны биләгән вазыйфасыннан азат итүне китереп чыгаручы хокук бозу булып торса, билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәттән азат итү.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2016 елның 23 апрелендәге
Х-4 номерлы карары белән
расланды

**«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре,**

**чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырырга тиешле вазыйфалар исемлеге**

1 Бүлек. Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфалары
1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфасы
Совет аппараты җитәкчесе.
2. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфасы
Бүлек башлыгы.
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары
Бүлек башлыгы урынбасары;
муниципаль район Башлыгы ярдәмчесе.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфасы
Бүлекнең баш белгече.

2 Бүлек. Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфалары
1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Башкарма комитет җитәкчесе;
Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары.
2. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы;
башкарма комитет органы җитәкчесе.
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары
Башкарма комитет башлыгы урынбасары;
мөстәкыйль бүлек башлыгы урынбасары.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Бүлекнең, башкарма комитет органы баш белгече;
бүлекнең, башкарма комитет органының әйдәүче белгече.

3 Бүлек. Башка җирле үзидарә органында, башка җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфалары

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе;
башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары.
2. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфасы
Мөстәкыйль бүлек башлыгы.
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфасы
Бүлек башлыгы урынбасары;
3. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфасы
Әйдәп баручы белгеч.